**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 12 декабрендәге 4404 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2021 елның 3 сентябрендәге 2189 номерлы**
**«Казан шәһәренең административ комиссияләрен**
**төзү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 3 сентябрендәге 2189 номерлы «Казан шәһәренең административ комиссияләрен төзү турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 1 апрелендәге 924 номерлы, 2022 елның 18 июлендәге 2286 номерлы, 2023 елның 2 февралендәге 287 номерлы, 2023 елның 22 мартындагы 827 номерлы, 2023 елның 27 октябрендәге 3241 номерлы, 2025 елның 15 маендагы 1476 номерлы, 2025 елның 17 июнендәге 1838 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Казан шәһәренең Авиатөзелеш, Киров, Мәскәү һәм Яңа Савин районнары административ комиссиясе составыннан А.И.Галкинаны чыгарырга;

1.2. Казан шәһәренең Авиатөзелеш, Киров, Мәскәү һәм Яңа Савин районнары административ комиссиясе составына комиссия әгъзасы сыйфатында Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратындагы административ комиссияләр эшчәнлеген оештыру идарәсенең 1 категорияле юрисконсульты Александрова Лилия Константиновнаны кертергә;

1.3. Казан шәһәренең Авиатөзелеш, Киров, Мәскәү һәм Яңа Савин районнары административ комиссиясе рәисе урынбасары Л.Ф.Золотованың вазифасы атамасын түбәндәге редакциядә бирергә: «Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратындагы административ комиссияләр эшчәнлеген оештыру идарәсенең бүлек башлыгы».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**